ЯКЫНАЯ АРАЛАР

Татарстан Президенты Төрекмәнстанда эшлекле сәфәрдә булды

> 2

САКЧЫЛ КАРАШ

Республиканың Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы елга йомгак ясады

> 2

АЛДАН КАЙГЫРТАСЫ

Милли Шура чираттагы җанисәпкә бүгеннән әзерләнергә чакырды

> 3



ХА-ХА-ХАНӘ

Кызык-мызык, булмас димә, фототөрткеләр – монда

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 9 (28976) | Шимбә | 21 гыйнвар | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

СЕЗ ИҢ КИРӘК КЕШЕ ИКӘНСЕЗ!

Күңел җылысы белән

Безнең заман геройлары. Махсус хәрби операция зонасында булып кайткан медицина хезмәткәрләре турында Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин шулай диде. Дан-шөһрәт эзләп түгел, Гиппократ антына тугрылык хакына һәм йөрәк кушуы буенча барган бит алар анда. Хезмәтләренә – хөрмәте дә. 59 табиб белән «Ливадия» шифаханәсендә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе һәм депутатлар очрашты. Хезмәтләре, күргәннәре турында ни ди соң алар?

tatarstan.ru

Күз яшьләре аша рәхмәт

Республика клиник хастаханәсе табибы Илфак Ярмиев Лисичанск шәһәренә иң беренчеләрдән булып барган медицина хезмәткәрләренең берсе. Ул анда «Күчмә сырхауханә» төркеме белән җитәкчелек иткән. Төркемдә исә Республика клиник хастаханәсе һәм 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе белгечләре. Үзләре белән – 9 тонна дару, медицина кирәк-яраклары, зур тәҗрибә һәм... ярдәмләшү теләге! Татарстан белгечләре ай ярымнан артык вакытларын шунда үткәрә. Илфак Ярмиев сүзләре белән әйтсәк, кыр һәм стресс шартларында.

– Бер кеше генә анда бер ни эшли алмас иде. Мин үзем белән барган хезмәткәрләргә – машина йөртүчедән алып табибка кадәр рәхмәтле. Алар минем өчен һәркайсы герой һәм чын батырлар. Без Хөкүмәт, республика җитәкчелеге, Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан куелган бурычны төгәл үти алдык дип сөенәм. Тыгыз элемтәдә тордык бу җәһәттән. Мобиль сырхауханәне алып барып кую гына түгел, анда эшне оештырып, җайлап җибәрү дә кирәк иче әле. Нинди җиргә барасын да белеп бардык бит... – ди ул. – Андагы халык башта безне шикләнебрәк кабул итте. Иң беренче сораулары: «Ә сезгә ничә сум акча түлисе?» Шул сүзләре белән гаҗәпләндерделәр! Аларда медицина бөтенләй юк дәрәҗәсендә бит. Халыкның сораулары, сырхаулары күп иде. Тикшерү генә түгел, чын медицина ярдәмен күрсәттек без. Мондый медицинаны күргәнебез дә юк иде, диделәр. Алар безгә елап рәхмәт укыды. Бу рәхмәтләр – хезмәтебезнең нәтиҗәсе күрсәткечедер, шулаймы?

Әңгәмәдәшебез әйтүенчә, үз гомерләре өчен түгел, диверсия булмасмы дип курыкканнар. Анда яшәүчеләр Татарстанны бик яраталар, ди табиб.

Лисичанск шәһәрендәге Татарстан вәкилләре (Евгений Варакин һәм аның командасы. – **Авт**.) көнне төнгә ялгап, нәтиҗәле эш башкара.

Бар нәрсә дә чагыштыруда беленә бит. Әнә, Илфак Ярмиев тә: «Тормыштан зарланган кешеләрне шунда бер көнгә булса да алып барып кайтырга кирәк, дим. Чагыштыру өчен. Оҗмахта яшәгәнебезне аңлау өчен... Без шөкер итә белмибез. Без ничек, ә алар ничек...» – ди.

Очрашуда Россиянең танылган хирургы, Дәүләт Думасының Сәламәтлек саклау комитеты рәисе, «Бердәм Россия» партиясенең махсус операциягә үз ихтыяры белән киткән беренче депутаты Дмитрий Хубезов та бар иде. Демобилизацияләгәннән соң хәрби госпитальгә аның урынына улы Леонид килгән. Дистәләгән кеше гомерен саклап калган хирург: «Ярдәм көткәннәргә булышу һәм үз илеңне яклау – иң зур бәхет. Махсус хәрби операция зонасында без, биргәнгә караганда, күбрәк алдык. Ул – кешеләр ышанычы», – диде.

Хезмәт күрсәтү түгел, ярдәм итү. Хәрби операция зонасында эшләп кайткан табиблар үз эшләре турында шулай ди. ДРКБ педиатры Эльмира Номина узган елның декабрендә Лисичанскидан кайткан. «Куркыныч булдымы?» – дип еш сорыйлар. Эшебез шулкадәр күп булды, хәтта куркырга да вакыт булмады», – ди педиатр.

Горурлык

– Лисичанск шәһәренә сәфәр минем өчен узган елның иң зур вакыйгасы булды. Чикне узу белән, безгә сак булырга куштылар. Безнең табиблар анда үзләренең һөнәри һәм гражданлык бурычларын батырларча үти. Аларга бик катлаулы шартларда эшләргә туры килә. Без киләбез дә китәбез, ә шәһәр халкы шул куркыныч шартларда яшәүләрен дәвам итә. Аларның яше дә, карты да: «Без сезнең табиблар ярдәме белән генә исән», – ди. Сез аларга өмет бирдегез, – дип мөрәҗәгать итте Татьяна Ларионова табибларга очрашуда.

Махсус хәрби операция башланганнан бирле, бу зонада республиканың 18 медицина оешмасыннан 79 медицина хезмәткәре булып кайткан. Күпчелеге кат-кат барган әле. Татарстанның сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков әйтүенчә, бүген андагы халыкка 19 медицина хезмәткәре ярдәм күрсәтә. Гомумән әйткәндә, табиблар көн саен 100дән 120 кешегә кадәр кеше караган, ике ай эчендә 4 меңнән артык балага медицина ярдәме күрсәткән.

– Бу шартларда эшләү дәверендә без тагын да көчлерәк һәм татуырак булдык, бердәм командада эшли башладык, – диде министр. – Хәрби операция зонасыннан кайткач та, табиблар: «Тагын кайчан Донбасска барабыз? Безнең анда пациентлар калды», – диде.

Табибларга Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да рәхмәт әйтте.

– Табиблар һәм медицина хезмәткәрләре – бүгенге көн геройлары. Алар моны көндәлек хезмәтләре белән исбатлый. Бүгенге вазгыять безнең нинди ярдәмчел һәм кеше кайгысына битараф булмаган халык икәнебезне тагын бер кат күрсәтте. Сезнең һөнәри осталыгыгыз һәм кулыгыздан килгәнчә ярдәм итәргә тырышуыгыз кешеләр йөрәгендә рәхмәт һәм горурлык хисләре уята, – диде ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА,
Ләйсән САФИНА

50 мең гариза кергән

Татарстан Социаль фондына йөкле хатын-кызлар һәм 17 яшькә кадәрге балалы гаиләләрдән бердәм пособие алуга 50 мең гариза кергән. Фонд башлыгы Эдуард Вафин әйтүенчә, белгечләр, мөрәҗәгать итүче турында дөрес мәгълүматлар җыю өчен, һәр гариза буенча төрле ведомстволарга 30дан артыграк запрос җибәрә. Шуннан соң, мәгълүматлар эшкәртелеп, тиешле карар кабул ителә. Гариза 10–30 эш көне эчендә карала. Җавап шәхси кабинетка юллана.

3 яшькә кадәрге беренче балага пособие түләү буенча да гаризалар кергән. Хәзер ул, яңа кагыйдәләр буенча, бердәм пособие рәвешендә рәсмиләштерелә. Бала 2023 елга кадәр туган очракта, түләү иске шартлар буенча: мөлкәтне исәпкә алмыйча, гаилә кереме югарырак булган очракта да рәсмиләштерелә.

Яңа пособие яшәү минимумыннан кимрәк керемле гаиләләргә бирелә. Тагын бер шарты: балалар һәм ата-аналары Россия гражданлыгына ия булып, безнең илдә яшәргә тиеш. Түләү билгеләнгәндә, гаиләнең керемнәре һәм милке, шулай ук ата-ананың мәшгульлеге исәпкә алына.

Сикәлтәле түгел юллар

Быел Татарстанда «Сыйфатлы имин юллар» илкүләм проекты буенча, яңа технологияләр нигезендә, 133 юл һәм күпер төзекләндереләчәк.

Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы хәбәренә караганда, 2020–2022 елларда республикада шушы проект нигезендә барлыгы 199 юл объекты тәртипкә китерелгән. Асылда яңа стандартлар буенча эшләнгән асфальт-бетон катнашма кулланыла. Күпер түшәмәләре дә заманча чыдам материаллардан эшләнелә.

Автомобиль юллары һәм күперләр җирле минераль, композит материаллар, асфальт-бетонның төрле төрләре, заманча саклагыч һәм гидроизоляция системаларын куллану нигезендә төзекләндерелә. Боларның барысы эшне тизрәк тотуга, шулай ук юл түшәмәсенең ныклыгын арттыруга ярдәм итә.

Узган елда республикада илкүләм проект буенча ремонтланган барлык 68 объектта яңа технологияләр кулланылган. Илкүләм проектлар, Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча, 2019 елдан бирле тормышка ашырылып килә.

Татарстанда 53 мәчет төзелә

Хәзерге вакытта Татарстанда 53 мәчет төзелә. Диния нәзарәтенең еллык хисабыннан күренгәнчә, узган елда республикада 14 мәчет ачылган. Шул исәптән Казанда – «Әхмәтзәки» һәм «Рауза» мәчетләре.

Шулай ук узган елда республикада 3 мәгърифәт үзәге: Арчада – Габдулла Тукай исемендәге, Кукмарада – «Һидаят» һәм Яңа Чишмә районында үзәк эшли башлаган. Моннан тыш 5 намаз бүлмәсе, шул исәптән Казан ЦУМында һәм Балалар республика клиник хастаханәсендә (ДРКБ) булдырылган.

Исегезгә төшерәбез: 2022 елның маенда Казанда «Кырлай» паркы урынында Җәмигъ мәчете төзелешенә тәүге нигез ташы салынды. Чара Болгарда ислам динен кабул итүгә 1000 ел тулуга багышлап уздырылды.

Тормыш кыйммәтләнгән

Татарстанда узган елның декабрендә бәяләр алдагы елның шушы ук аендагы белән чагыштырганда 11,4 процентка артыграк булган. Татарстанстат мәгълүматларына караганда, бу айда хезмәт күрсәтү бәяләре барыннан да күбрәк кыйммәтләнгән – 11,7 процентка. Моннан тыш сәнәгать товарлары хакы 11,4 процентка арткан.

Азык-төлек бәясе исә 11,1 процентка күтәрелгән. Әлеге күрсәткечнең иң түбән булуы яшелчә бәясенең нык үсмәвенә (нибары 0,5 процентка кыйммәтләнгән) бәйле.

Шул ук вакытта бер ел эчендә: гыйнвардан декабрьгә кадәрге чорда бәяләр уртача 14 процентка үскән: азык-төлек – 16,3%, сәнәгать товарлары – 14,6%, хезмәт күрсәтүләр бәясе – 10,2 процентка.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Актуаль тема

Иске яңаны алыштыра

ЧИГЕНГӘН АВЫРУЛАР КАБАТ БАШ КАЛКЫТА

Короновирус чигенде, тик иркен сулыш алырга иртәрәк, чөнки эпидемия вакытында күләгәдә калып торган авырулар кабаттан баш калкыткан. Грипп, кызамык, тычкан бизгәге – агымдагы һәм алдагы елларда аерым игътибар бирелергә тиешле авырулар менә шушылар.

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе Марина Патяшина еллык коллегия башында журналистлар белән аралашканда ук: «Уңышлардан бигрәк, бездән зур игътибар сорый торган мәсьәләләргә аерым басым ясалачак», – дип кисәтеп куйган иде. Чыннан да, елга йомгак ясау белән бергә проблемалар барланды һәм аларны чишү юллары күрсәтелде.

– Короновирус белән авыручылар саны күп булса да, авыру җиңел формада уза, шуңа күрә пандемия бераз чигенә дип әйтә алабыз, – диде ул. – Ләкин пандемия вакытында бераз «йокы» халәтендә булган авырулар баш калкыта башлады.

Марина Патяшина сүзләре буенча, болар – беренче чиратта прививка профилактикасы белән бәйле йогышлы авырулар.

– Безне кызамык буенча вазгыять бик нык борчуга сала, – диде белгеч. – Хәзер Россия субъектларында әлеге авыруның 4 зур очрагы ачыкланды. Шул исәптән, безнең күршеләребездә дә. Кызамык – бик йогышлы һәм тиз тарала торган авыру. Әгәр халык арасында кызамыкка каршы прививка ясамаучылар бар икән, ул бик тиз арада таралырга сәләтле.

Санитар табиб сүзләренчә, узган ел Татарстанда Таҗикстаннан кайткан бер кешедә кызамык булуы ачыкланган. Шул ук вакытта авыру белән контактта булган 33 кеше прививка ясатудан баш тарткан. Шуңа күрә елга йомгак ясау чарасында район һәм шәһәр поликлиникаларында өлкәннәргә һәм балаларга прививка ясауга зур игътибар бирергә кирәклегенә кат-кат басым ясалды. Әйтик, Татарстанда кызамыкка каршы вакцина халыкның 95 процентына ясала. Тик шул ук вакытта бу прививканы ясаудан баш тартучылар да бар. Андыйлар Арча, Чистай, Аксубай, Нурлат, Чирмешән, Баулы районнарында иң күбе. Гомумән алганда, Питрәч районы – балаларга ясала торган, Апас, Зәй, Югары Ослан, Нурлат, Буа районнары һәм Чаллы шәһәре өлкәннәргә ясала торган прививкалар буенча планны тутырмаган.

Игътибар күрсәтелергә тиешле тагын бер авыру – тычкан бизгәге. 2022 елда моның белән авыручылар 3,7 тапкыр күбәйгән. Бу – күпьеллык уртача күрсәткечләр белән чагыштырганда, 28 процентка арту дигән сүз.

– Кызганыч, 2023 елга фаразлар шулай да бик начар. Чөнки кимерүчеләр һәм алар арасындагы авырулар саны бик күп. Шунлыктан территорияләрне вакытында һәм сыйфатлы итеп эшкәртүгә һәм шәхси гигиена таләпләрен үтәүгә зур игътибар бирергә кирәк, – диде ул.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз



Александр КОЗЛОВ, Россиянең табигый байлыклар һәм экология министры:

Россиялеләр ел саен 17,9 миллион тонна азык-төлек калдыкларын ташлый, шул ук вакытта бер россиялегә уртача 80 кг ташлана торган азык туры килә. Бу очракта да үзеңнән башларга кирәк. Ягъни азык-төлек сатып алуга аңлы карарга.

(«Российская газета»дагы әңгәмәсеннән)

РОССИЯДӘ – ГРИПП

Россиядә яшәүче 18 һәм аннан өлкәнрәк яшьтәгеләрнең һәр өченчесе быел көз – кыш айларында грипп белән авыруын әйткән. Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре шуны ачыклаган:

39%	хатын-кызлар
32%	ир-атлар
20%	гриппка каршы прививка ясаткан
58%	«дуңгыз гриппы»н йоктырудан курка

ЖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Вазгыять кая бара?

Швейцариянең Давос шәһәрендә шушы атнада узган традицион Бөтендөнья икътисадый форумында кешелек алдына якын араларда килеп басачак өч төп һәм дә глобаль проблемаларны санап чыктылар. 2033 елга кадәр булган перспективада климатик үзгәрешләрнең кискенләшәчәге, шул вакыт аралыгында кеше сәламәтлегенә зыян салырдай яңа эпидемия, пандемияләр яралу ихтималының зурлыгы һәм дә туктамаган кораллы конфликтлар, җирдә куркынычсызлык кимү аркасында туачак глобаль милитаризация.

Соңгы куркынычка тукталыйк. Җирдә, аның төньяк ярымшар дип аталган ягында чыннан да яңа милитаризация баш калкытып маташа. Милитаризация ул – икътисадны хәрби рельсларга күчерү. Ул – азык-төлек, халык куллану товарларының күләме, ассортименты кимеп, өстенлекнең хәрби продукциягә бирелүе – патрон, снарядлардан башлап, стратегик ракеталарга чаклы барысын да чамасыз күләмдә күбрәк җитештерә башлау. Ул – шул ук ашкынып кораллану. Милитаризация дигәндә, шунысы бик тә шөбһәле: «Беренче актта сәхнә читендә мылтык эленеп тора икән, соңгысында ул атарга тиеш», – дигән кебек, корал күбәйгән саен аны куллану куркынычы да пропорциональ рәвештә арта.

Украинадагы конфликт атом-төш коралыннан башка тагын нинди корал системалары бар, барысын да сорап, таләп итеп, үзенә суырып тора. Без яшәгән илдә генә түгел, Европаның аерым дәүләтләрендә дә, океан артында да корал кою тизләнеш алып ята. Дәүләтләр арасында үзара ышаныч калмау сәбәпле, һәркем сугыш учагына утын ташып кына калмыйча, кемдер саклану-оборонага, кемдер хәтта ки һөҗүмгә дә әзерләнә. Мондый начар сценарийның күптән, «салкын сугыш» елларыннан бирле туганы юк иде.

Милитаризациянең глобаль сугыш китереп чыгармаган тәкъдирдә дә миллионнарга кагылачак нәтиҗәсе ул, әлбәттә инде, халыкның тормыш дәрәҗәсе төшү. Акылдан язып корал койганда, дәүләтләр гадәттә гади кеше, аның мәнфәгатьләре, ихтыяҗларын икенче генә түгел, бишенче планга күчереп куя. Әмма тормыш сыйфаты начарлану бар тарафларда да бер үк төрле, бер чама була алмый. Барысы да иленә, җиренә карап. Чөнки икътисад торышы, икътисадый егәр төрле дәүләтләрдә төрлечә. Корал коючылар арасында маена чыдаша алмаган хәлләр булган кебек, тормыш дәрәҗәсе дигәндә, авызын ачса, үпкәсе күренгәннәр, аягын юрганга карамыйча сузганнар да бар. Уртаклык шунда: мин-минлек белән амбицияләр иленә, икътисадына карамастан, күбесендә чиктән ашкан. Шул мин-минлек күп вакыт бәлагә илтә дә инде.

Ашкынып кораллану дигәндә, мәсәлән, шул ук американнарга бер дә артыгын көчәнәсе түгел. Элек тә шулай иде, хәзер дә. Шуны яхшы белгән хәлдә, алар дистә елларга сузылган «салкын сугыш» дәвамында СССР дигән илне корал кою ярышына ымсындырып торды. Хәер, АКШның беренче идеологик һәм хәрби дошман санаган СССРны, аның үзсүзле җитәкчеләрен артыгын котыртасы, кыстасы да булмагандыр. Нәтиҗәсе һәммәбезгә мәгълүм. Аларга карап, аларча кыланып, ярышып, ахырда без икътисадыбызны берьяклы иттек, имгәттек. Союзның юкка чыгуында да шул фактор төп рольләрнең берсен уйнады. Кемнәрдер иртәгә үк убылу, мескенлеккә чыгу, бетү юраса да, без яратмаган Сэм агай, телибезме-теләмибезме, инде менә ярты гасырдан артык дөньяның беренче икътисады. Дөнья икътисадындагы өлеше 20–25 процентка җиткән ил (чагыштыру өчен Россиянеке – 1,5–2,0 процент) алай тиз генә җәһәннәмгә олага алмый. Кем әйтмешли, үгезгә чуан чыкмый. Озын сүзнең кыскасы, «авырлык категорияләре» нык аерылу сәбәпле, элек баскан тырмага яңадан китереп басудан саклансак иде, диясе килә. АКШны, аның икътисадый потенциалын гына түгел, итәк астыннан ут йөртү сәләтен бәяләп бетермәү безгә бик тә кыйммәткә төшәргә мөмкин.

Корал кою темасыннан чыкмыйча, икътисадый куәте буенча дөньяда икенче урында торган Кытайга карыйк. Күк асты иле, геосәясәт дигәндә дә, кораллану дигәндә дә, үзен шактый ипле тота, дию дөрес. Ә бит алардагы егәр белән, артык тирләмичә генә, мәсәлән, боеголовкалар, стратегик ракеталар санын Россия белән АКШтагыча итеп, тигезләп кую берни түгел. Тик алар аны эшләми. Кытай, гомумән дә, тышкы сәясәткә караганда күбрәк эчкесе белән шөгыльләнә. Һәм бик дөрес эшли. Мәктәп дәреслекләреннән хәтерлим: аларның фәлән йөз ел элек булган чикләре, картада сарыга буялган биләмәләре якынча бүгенге дәүләт чикләре, бүгенге биләмәләргә тәңгәл. Ягъни ул олы халык яулап алулар, экспансия белән артык мавыкмаган. 6–7 мең чакрымга сузылган, саклану максатыннан торгызылган Бөек Кытай стенасы да моңа саллы дәлил…

Без гомер иткән илгә дә чималга бәйлелектән котыласы, фәнни потенциалны үстереп, технологияләр тудыручы, аларны тормышта актив кулланучы дәүләткә әвереләсе, халыкның тормыш сыйфатын алдынгы илләр дәрәҗәсенә җиткерәсе иде…

Әлегә исә пенсия алучы, бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә генә түгел, бар булган халыкка нефть белән газдан кергән табышның кискен кимемәвен теләргә генә кала. Чикләүләр аркасында, «кара алтын» дигәнебезнең саллы дисконт белән сатылуы гына җитмәгән, сату күләмен дә эмбарго кертеп, буып маташалар. «Кара көн»гә дип җыйган Милли муллык фонды, алтын-валюта запаслары да төпсез кое түгел. Димәк, мәгълүм низагның, аның белән бергә хәтсез ил кереп киткән милитаризациянең берәр хикмәт белән туктавына өмет иткән җәһәттә дә, барыбызга да, матди яктан да, рухи яктан да, бик үк яхшы булмаган сценарийларга, вазгыятькә әзер тору ләзем.

«Без һәрвакыт якын булган»

Ашхабадта Төрекмәнстан һәм Татарстан Президентлары очрашуында әнә шундый фикер яңгырады. Элемтәләр бүген дә ныклы. 2021 елда ике арада товар әйләнеше 78 миллион долларга җиткән әнә. Пандемия һәм барыбызга да билгеле булган сәбәпләр генә күрсәткечләрне бераз киметкән. Алга таба хезмәттәшлекне тагын да арттырачаклар.

Билгеле булганча, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Төрекмәнстанда ике көнлек эш сәфәренә барды. Ул Ашхабадта ил делегациясе составында Төрекмән – Россия бизнес форумында катнашты, эшлекле очрашулар үткәрде. Халыкара җыен ике яклы сәүдә-икътисадый һәм сәнәгать хезмәттәшлеген арттыру өчен уздырыла. Быел анда дәүләт оешмаларыннан һәм шәхси компанияләрдән 300дән артык вәкил катнашкан.

Рөстәм Миңнеханов җыенда катнашучыларга сәламләү сүзе белән мөрәҗәгать итте.

– Россиянең сәнәгать өлкәсендә алдынгы төбәкләренең берсе буларак, Татарстан ике ил арасында хезмәттәшлекне үстерүдә актив катнаша, – диде ул. – Төрекмәнстанда күп еллар дәвамында безнең әйдәп баручы компанияләр – КАМАЗ, «Татнефть», Казан вертолет заводы, КЭР-холдинг, суднолар төзү компаниясе һәм башкалар уңышлы эшли.

Аерым алганда, Казан вертолет заводы Төрекмәнстанга «Ансат» вертолетларын озаткан. Яшел Үзәннең суднолар төзү заводы бирегә тиз йөрешле пассажир суднолары китергән. КЭР-холдинг Төрекмәнстан белән газ турбинасы мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итә. Президент әйтүенчә, 2021 елда ике арада товар әйләнеше 77,5 миллион доллар тәшкил иткән. «Кызганыч, пандемия һәм башка шартлар соңгы арада товар әйләнеше күләмен киметте, әмма аны үстерү юнәлешендә актив эш алып барыла», – диде Президент.

tatarstan.ru

Президент Төрекмәнстанда яшәүче татарларга даими ярдәм күрсәтүләре өчен дә рәхмәт җиткерде. Бүген биредә якынча 15 мең татар яши. Татарстанда исә 3 меңгә якын төрекмән гомер итә. Рөстәм Миңнеханов каршы якны Казанда узучы KazanSummit халыкара форумында катнашырга да чакырды.

Төрекмәнстан Президенты белән очрашу барышында Рөстәм Миңнеханов Сердар Бердымөхәммәтовка Россия – Төрекмәнстан хезмәттәшлеген ныгыту кысасында, Татарстан белән элемтәләрне үстерүгә әһәмият бирүе өчен рәхмәт әйтте.

– Тарихи күзлектән чыгып караганда, татарлар һәм төрекмәннәр һәрвакыт якын булган. Россия – Төрекмәнстан мөнәсәбәтләре стратегик әһәмияткә ия. Безнең җитәкчелек даими элемтәдә тора, – диде ул.

Очрашу барышында машина төзелеше, нефть һәм газ химиясе, цифрлаштыру кебек юнәлешләр буенча элемтәләрне ныгыту турында фикер алыштылар. Рөстәм Миңнеханов мәдәният, фән һәм мәгариф өлкәләрендә хезмәттәшлекне арттыруның әһәмияте турында да аерым искә алды.

– Татарстан югары уку йортларында белем алучы төрекмән студентлары саны елдан-ел арта. Республикада 6 мең 212 кеше укый. Бу – республикада белем алучы чит ил студентларының дүрттән бере диярлек. Төрекмәнстан студентлары сан ягыннан Татарстанда укучы чит ил студентлары арасында беренче урында, – диде Президент.

Эш сәфәре кысасында Президент Аркадаг шәһәрендә Җәмигъ мәчетенә нигез салу тантанасында да катнашты. Аллаһ йорты берьюлы 5,5 мең кешене сыйдыра алачак. Илнең тәүге «акыллы шәһәре» булып саналучы Аркадаг шәһәре үзе дә яңа әле. Аны 2019 елда төзи башлаганнар. Биредә 70 мең кеше яшәячәк. Рөстәм Миңнеханов төрекмән халкын Җәмигъ мәчетенә нигез салыну белән котлады.

– Бу – Төрекмәнстан гына түгел, бөтен мөселман халкы өчен зур вакыйга. Биредә мәдрәсә дә булачак. Безнең телебез дә, гореф-гадәтләребез дә охшаган. Төрекмәнстанның елдан-ел үзгәрүен күрәбез. Зирәк, акыллы җитәкчелек булмаса, бу мөмкин булмас иде. Татарстан сезнең уңышларыгызга бик шат, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент Төрекмәнстанда Гекдепе шәһәрендәге Сапармурат Хаҗи мәчетендә дә булды.

Бер Казанда гына түгел

Татарстан Дәүләт Советында республика Иҗтимагый палатасының яңа – җиденче составы беренче утырышын уздырды. Көн тәртибендә берьюлы берничә мәсьәлә каралды.

Утырышта Иҗтимагый палата вәкилләре, Татарстан Парламенты Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин һәм Президент Администрациясе рәисе Әсгать Сәфәров катнашты.

Иң беренче эш итеп катнашучылар Иҗтимагый палатаның яңа рәисе өчен тавыш бирде. Бу вазыйфага кабаттан Зилә Вәлиеваны сайлады алар. Шуннан соң Иҗтимагый палата рәисенең яңа урынбасарлары билгеләнде. Әлеге вазыйфага Казан дәүләт энергетика университетының проректоры Ирина Әхмәтова, Татарстан халыкларының Яшьләр ассамблеясы җитәкчесе Тимур Кадыйров һәм В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновацион университет ректоры Асия Тимирясова билгеләнде.

Моннан тыш, Иҗтимагый палатаның җиденче составы тугыз комиссия, аларның эшчәнлек юнәлешләрен, даими вәкилләрен һәм җитәкчеләрен тәгаенләде.

– Бүген Иҗтимагый палата яңарыш кичерде, «яшәрде», әмма аның нигезе – гомерләрен халык белән эшләүгә багышлаганнар әле дә безнең белән, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. Шуннан соң ул Иҗтимагый палатаның абруе зур булуын искәртте. – Мөһим карарлар кабул иткәндә без сезнең белән киңәшләшеп эшлибез, чөнки нәкъ менә сез халык белән тыгыз элемтәдә торасыз. Киләчәктә Татарстан башкаласында гына түгел, республика районнарында да актив эшләрсез дип өметләнәм. Бу – бик мөһим мәсьәлә. Күп нәрсә районнарга барып җитми. Күптән түгел Әгерҗедә булып кайттым һәм менә шундый тәэсир калды. Казанда гына утырып бу мәсьәләне хәл итеп булмаячак. Районнарга чыгып, кешеләр белән очрашып, аларны тыңлап һәм алар белән сөйләшеп эшләвегезне сорыйм.

Парламент рәисе алтынчы составның эшчәнлегеннән канәгать калуын да белдерде. Яңа составка исә буыннар арасындагы элемтәне саклау, күп еллар буе тупланган тәҗрибәне куллану бурычларын да куйды.

Иҗтимагый палата рәисе Зилә Вәлиева, Фәрит Мөхәммәтшинның «яшәрү»гә кагылышлы сүзләрен җөпләп, яңа составта яшьләрнең күп булуын билгеләп үтте.

– Миңа калса, бу – бик мөһим. Иҗтимагый палата – гражданлык активлыгы мәктәбе дә бит ул, – диде ул.

ИСКЕ ЯҢАНЫ АЛЫШТЫРА

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Белгеч кимерүчеләргә һәм чебен-черкиләргә каршы профилактикалау чараларын иртә яздан ук эшләргә кирәклеген әйтте. Узган ел республиканың 19 районы (Югары Ослан, Саба, Буа, Арча, Кайбыч, Чүпрәле, Мөслим, Мамадыш, Әтнә һәм башкалар) бу эшләрне бары тик 20 майдан соң гына башкарган.

Чагыштырмача яңа төр авырулар баш калкыту белән бергә, коронавирус аркасында бераз чигенеп торган чирләр кабаттан үзләрен күрсәтә башлады. Марина Патяшина әйтүенчә, узган ел республика халкы 28 төрле йогышлы авыру белән авырган. Әлеге сезонда татарстанлыларга барыннан да бигрәк «дуңгыз гриппы»ннан дәваланырга туры килгән.

– Пандемиянең өченче елына безнең өчен гадәти булган авырулар үз урынына әйләнеп кайта башлады. Бигрәк тә ике ел очрашмаган грипп үзен актив рәвештә күрсәтте. Бүген ул йогышлы авырулар арасында 68 процентны алып тора. Шуңа күрә әлегә грипп белән бәйле вазгыятьне тыныч дип әйтеп булмый. Эпидемиологик вазгыять мартка кадәр булыр дип уйлыйм, – диде ул.

Аның каравы кадрлар мәсьәләсендә тотрыклылык күзәтелә. Баш санитар табиб сүзләренчә, узган ел эш урыннарын калдырып китүче табиблар булмаган диярлек.

– Күрәсең, кайбер хезмәткәрләр менә шундый режимда эшләргә күнеккәндер, – диде ул, моның сәбәпләрен шәрехләп. – Алгы сызыкта эшләп арыган табибларның штат режимына күчүе дә хәлне тотрыкландырды. Шуңа күрә бүген Роспотребнадзор хезмәтендә кадрлар мәсьәләсе белән авырлыклар юк.

Утырышта катнашкан Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе хезмәткәрләренең эшен югары бәяләде һәм куелган бурычларны башкарып чыгар өчен уңышлар теләде.

Зөһрә САДЫЙКОВА

АЛЕКСАНДР ШАДРИКОВ:

«БЕРГӘ ЭШЛӘСӘК, ТӘРТИП БУЛАЧАК»

Нәтиҗә

Су кадере тагын да артачак! Татарстанда 1968 елдан бирле 3133 чишмә-күл юкка чыккан. Югалтуларның сәбәбе дип, аларны күмеп, төзелеш эшләре башкаруны атыйлар. Бу хакта Татарстан Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының еллык киңәйтелгән утырышында сөйләделәр.

Тармак министры Александр Шадриков сүзләренә караганда, монда борчылырлык урын бар. Министр елга нәтиҗә ясап, эшләнгән эшләрне дә барлады, экологик проблемаларга да тукталды.

– Безне сулыкларның кимүе, пычрануы, су чистарткыч корылмаларның төзелеп тә, тиешенчә эшләмәве, җир асты байлыкларыннан рөхсәтсез куллану, чүплекләр дә бик борчый, – диде ул. – Күпме генә эшләр башкарылып та, чүпкә бату бу инде төбәк операторларының эшчәнлегенә дә бәйле. Шуларны контрольгә алырга кирәк. Күптән түгел Чаллы шәһәрендә 7 гектарга якын мәйданда рөхсәтсез оештырылган чүплек табылды. Аның табигатькә китергән зыяны 580 миллион сумны тәшкил итә.

Александр Шадриков чүп турында сөйләгәндә, район башлыкларына да үтенечен җиткерде. Бер җирне матурлап, икенчесендә чүплек ясамагыз, диде ул. Баксаң, экологлар районнардагы вазгыятьне сорап мөрәҗәгать итсәләр, берәү дә беркетмә җибәрми икән. Түрәләр уйлавынча, аларда бар да тәртиптә. Ә менә министр, юк, ди.

– Район башлыклары гаризасы буенча без чистарту корылмалары төзедек. Республикада 174 корылма төзелде. Әмма аларның эшчәнлеге хакында хисап сорагач, безгә 32 районнан бу хакта бернинди җавап килмәде. Димәк, яшерер нәрсәләр бар. «Арча» оешмасыныкы кебек. Бу оешмага күпме генә кисәтү ясалса да, ул әле дә сулыкларны пычратуын дәвам итә. Кайсы гына районда эш башкарсалар да, калдыкларын инеш-күлләргә агызалар, – ди Александр Шадриков. – Уртак тел табып, табигатькә китергән зыяны өчен, бу оешмага сусаклагыч корылмаларны төзекләндерергә кушылган иде. Әмма ул аны әле дә үтәмәде. Бу оешма башта инешләрне, аннан Казансу елгасын, хәзер инде Иделне пычрата.

Елгалар дигәннән, быел Нокса елгасын чистартачаклар. Бу эш «Уникаль су объектларын саклау» федераль проекты кысасында башкарылачак. Елганы чистарту һәм яр буйларын төзекләндерү өчен 9,5 миллион сум акча тотылачак.

Җир асты байлыкларыннан рөхсәтсез файдаланучы районнарга да шелтә белдерде Александр Шадриков. Республикада 311 файдалы казылмадан файдаланырга мөмкин. Әмма барысы да рөхсәт белән башкарылырга тиеш. Бу өлкәдә тәртип бозучылар шактый. Әйтик, узган ел җир байлыгын урлаучыларга бәйле 12 эш судка җибәрелгән.

Министр башкарыласы эшләргә дә тукталды. Агымдагы елда ләм басуларын бетерү максаты тора. Шулай ук су астындагы тик ятучы үткәргечләрне дә чыгарырга кирәк. «Иделне савыктыру» программасы да дәвам итәчәк. Әлеге дә баягы эчәргә яраклы су мәсьәләсен дә хәл итәргә кирәк. Александр Шадриков сүзләренчә, республика районнарында су запасын барлау буенча ревизия башланган. Экологлар 14 районда 1629 су скважинасын тикшергән инде. Шуларның 1181енең лицензиясе юк. Министр әлеге юнәлештә тәртип салырга кирәклеген әйтте.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Утырышта һава чисталыгын контрольдә тоту, сәнәгать оешмалары белән экологияне бергәләп кайгырту турында да сөйләделәр.

– Республика халкына рәхмәтлемен. Бергәләп эшләгәндә, уңышка да ирешәсең, башкарган эшең дә күренә. Соңгы биш ел эчендә халыктан килгән зарлар 2 тапкыр кимеде. Димәк, без дөрес юлда, – ди Александр Шадриков.

Татарстан Премьер-министр урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин министрлык эшен югары бәяләде. «Вода России» бәйгесендә ике ел рәттән 1 урынны алуларын югары дәрәҗәдәге эш нәтиҗәсе дип атады.

– Эре сәнәгать оешмалары күп булган саен, экологиягә игътибар тагын да арта, – ди ул. – Министрлыкның узган ел башкарган эшләре шактый. Биологик чистарту корылмаларын төзекләндерү, чүплекләрне рекультивацияләү, 50 елдан артык Куйбышев сусаклагычына комачау иткән ләм басуларын бетерү, нефть үткәргечләрен судан чыгару, Самосырово полигонындагы эшләр – болар барысы да илкүләм проектлар ярдәмендә башкарыла. Чистарту корылмалары да төзекләнделә. Әмма аның сыйфатлы эшләвен тәэмин итәргә кирәк. Алар экологиягә зыян салмаска тиеш!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

БҮГЕННӘН АЯК КИЕНӘСЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Җанисәп

Татар кимемәгән, исәпкә генә алынмаган. Җанисәп нәтиҗәләре игълан ителгәннән бирле бу фикерне гел ишетеп торабыз. Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасының бюро утырышында да сүз йомгагы әнә шуңа барып тоташты. Утырышта Милли Шураның узган елгы эшчәнлегенә йомгак та ясалды.

Ярты миллионы саналмаган

Күреп торабыз: соңгы җанисәп нәтиҗәләре көтелмәгән һәм канәгатьләндермәгән булуы белән тарихка кереп калырга охшап тора. Җавапларга караганда, сораулар күбрәк. Илдә татарларның 600 меңгә (!) диярлек кимүе аеруча ризасызлык уятты. Шушы санны ишеткәннән бирле бу коточкыч күрсәткечкә китергән сәбәпләрне барлыйбыз.

Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев фикеренчә, халык саны нәтиҗәләренә, нигездә, аның иң уңайсыз чорда – илдә коронавирус котырган чорда уздырылуы йогынты ясаса да, аны оештырганда эшләп бетермәгән «тап»лар да җитәрлек. Төбәкләрдәге автономия җитәкчеләре: «Җирле халык беркая китмәде», – ди. Шартлар да уңай булмады. Сан алучыларның күбесе фатирларга керә алмады», – диде Васил Шәйхразыев утырышта.

Белгечләрнең күбесе җитешмәгән татарларны быелгы җанисәптә үз милләтен күрсәтмәгән 16,5 миллион кеше арасыннан эзләү яклы. Россия академиясе Этнология һәм антропология институтының элеккеге директоры һәм Россиянең милләтләр эшләре буенча элеккеге министры Валерий Тишков фикеренчә, Россиядәге соңгы җанисәптә кимендә ярты миллион татар исәпкә алынмаган.

– Җанисәп пандемия, халык исәбен алучылар эшен җитәрлек дәрәҗәдә финансламау, Дәүләт хезмәтләре интернет-порталы аша халык исәбен алуга яхшылап әзерләнмичә күчү, гаммәви мәгълүмат чаралары һәм социаль реклама тарафыннан шундый мөһим кампанияне тулысынча игътибарсыз калдыру аркасында начар узды. 17 миллион кеше (барлык халыкның 13 проценты!) милләтен күрсәтмәде. Шуларның ким дигәндә 13,5 миллионы – руслар, 0,5 миллионы – татарлар, – дип язган Тишков социаль челтәрдәге сәхифәсендә.

Авыл да калышмый

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров җанисәп нәтиҗәләре игълан ителгән беренче көннән үк милләттәшләребез белән бәйле саннарның дөреслеккә туры килмәвен искәртеп килде. Конгрессның экспертлар комиссиясе бүген Россиядә яшәүче татарлар 5 миллион 500 меңнән дә ким түгел дип санап чыгарган. Хәер, татарлар яшәгән төбәк вәкилләре үзләре дә кәгазьдәге саннарның чынбарлыкка якын да килмәвен искәртә.

Әйтик, шул ук саннарга ышансаң, соңгы ун ел эчендә Оренбург өлкәсендә яшәгән татарлар саны 34887 кешегә кимегән. Бу – шул вакыт эчендә биредәге татарлар 23 процентка кимегән дигән сүз. Оренбург өлкәсенең Төбәк татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе Илдус Дәүләтов фикеренчә, чынлыкта төбәктәге милләттәшләребез саны күп дигәндә 10 процентка гына кимегән булырга мөмкин.

– Оренбургта татарлар 29,9 процентка азайган дип чыгардылар. Әмма бу саннар дөреслеккә туры килми. Чынлыкта бездәге татарлар күп дигәндә 10 процентка гына кимегәндер. Монда төп сәбәп – кеше факторы. Халык санын дөрес исәпләмәгәннәр. Шул ук авылда шул ук кешеләр яшәп ята бит. Алар бар, алар беркая да югалмаган. Һәркайсы үз урынында, – ди Илдус Дәүләтов.

Җанисәп нәтиҗәләре буенча Мәскәүдә, Чиләбе, Свердловск, Ульян, Оренбург өлкәләрендә татар халкының аеруча нык кимүе күзәтелә. Әйтик, шул ук Ульян өлкәсендә татарлар 38,5 мең кешегә кимегән. Өлкәнең татар милли-мәдәни автономиясе рәисе, Иҗтимагый палата әгъзасы Рәмис Сафин исә бу саннарга гаҗәпләнми.

– Бу саннардан трагедия ясамас идем. Ник дигәндә, җанисәпне оештырганда кытыршылыклар күп булды. Аның онлайн рәвештә узуы да йогынты ясады. Өлкән буын вәкилләре тиешенчә катнаша алмады. Өченчедән, моңа Ульян өлкәсендә катнаш никахларның күп булуы да йогынты ясады. Аларның балалары татар булып язылмый бит инде. Катнаш никахтан руслар туа, – ди ул.

Түбән өлкәсе татарлары конгрессының башкарма комитет рәисе Ринат Насыйров җанисәпне уздыру тәртибеннән дә, аның нәтиҗәләреннән дә канәгать түгел.

– Җанисәп «узганмы – узган» рухында башкарылган эш кебек булды. Элек халык санын алу күбрәк калаларда җитешсезлекләр белән узган булса, быел ул авылларда да бик түбән дәрәҗәдә үтте. Без үзебез дә 2010 елдан бирле күп ялгыш адымнар ясадык. Шул ук ипотека программасы аркасында авылларда яшәүче бик күп татар шәһәргә күченде. Шул рәвешле алар 90 процент руслар яшәгән җирлеккә килеп урнашты. Аларны үзебездә тотып калу өчен мәдәният, мәгариф буенча да эшләрне эшләп өлгермәде, – ди ул. – Аннары без зур шәһәрләр янында урнашкан татар авылларының акрынлап калага кушылып китүен дә сизми калдык. 1 мең кеше яшәгән, 90 процентын татарлар тәшкил иткән авылда 25 катлы 4–5 йорт пәйда булды. Шул рәвешле 90 процент татардан 10 процентка гына калдык. Аның өчен монда башка милләт вәкилләре килеп тулды. Мәктәп тә балалар бакчалары да башка дәрәҗәгә күчте. Безнең Кырымкүл авылында 1450 бала укый торган өр-яңа мәктәп төзелде. Шунда нибары 450 татар баласы укый.

Алга таба ни эшләргә?

Тарихчы Айрат Фәйзрахманов фикеренчә, җанисәп нәтиҗәләре шик уята икән, аерым төбәкләрдә, муниципалитетларда социологик тикшеренүләр уздырырга кирәк. «Аның нигезендә саннарда күпмегә хата киткәнен төгәл карый алабыз. Ә бездә мондый социологик тикшеренүләрнең 2015 елдан бирле уздырылганы юк инде», – ди тарихчы.

Ничек кенә булмасын, итәк-җиңнәрне җыеп, тагын ун елдан булачак чираттагы җанисәпкә бүгеннән үк аяк киенер чак. Васил Шәйхразыев фикеренчә, Россиядә 5,5 млн татар яши икән, Татарның үсеш стратегиясен һәр гаиләгә җиткерергә кирәк.

– Ничек кенә авыр булса да, безнең фикер һәр кешегә барып җитәргә тиеш. Катнаш никах булганда да, татар гаиләсе булып, балалар татар телен беләләр икән, шулай итеп халык санын арттырып була. Тарих аша татарларның бердәм булуын күрсәтергә кирәк. Оешмаларга барып, дөрес анализ ясарга кирәк. Ныклы аналитика булсын иде. Горур халык булып, башыбызны күтәреп алга барыйк. Барыбыз да гаепле дип, башны иеп йөрү дөрес булмас, – диде Милли Шура рәисе.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Нәтиҗә

Шикәр чире үзеннән-үзе бетми



vk.com

Татарстанда балалар арасында инвалидлык алучылар саны арта. Бүген республикада физик мөмкинлеге чикләнгән 16 мең 975 бала яши. Шуның 1989ын белгечләр 2022 елда ачыклаган. Бу хакта Татарстанның суд-медицина экспертизасы бюросының еллык эшчәнлегенә нәтиҗә ясап үткәрелгән киңәйтелгән утырышта әйттеләр.

– Пандемия чорында күп кенә документ эшләре гадиләштерелде. Физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләр инвалидлыкны алты айга онлайн документлар юллап озайтты. 2022 елның 1 июленнән элеккеге режимга кайттык. Хәзер авырулар экспертиза узар өчен юллама алып, үзләре безгә килергә тиеш, – ди Татарстанның суд-медицина экспертизасы бюросы җитәкчесе Ригель Низамов. – Узган ел без 16 мең 393 кешегә беренче тапкыр инвалидлык куйдык. Олылар арасында инвалидлыкка китерү буенча яман чир авырулары беренче урында тора.

Сабыйлар арасында психик тайпылышлар арту күзәтелә. Икенче урында нерв системасы авырулары тора. Тумыштан зәгыйфьлекләре булган балалар да аз түгел. Бәлки шуңа да утырышта катнашучылар сабыйларның сәламәтлеге хакында күбрәк сөйләште. Аларның сәламәтлегендәге үзгәрешләрне вакытында күреп алмыйлармы? Бу сорауны күпләр яңгыратты. Әти-әниләрнең игътибарсызлыгымы бу, әллә инде табиблар карап җиткермиме? 2020 елда яңа туган балаларга инвалидлык күбрәк куелса, быел исә 4 яшьтән узып киткәннәрнең беренче мәртәбә сәламәтлегенә бәйле җитди проблемалар барлыгы ачыкланган. Кыскасы, аларга да физик мөмкинлекләре чикләнгән дигән сүзне ишетергә туры килә.

Балалар арасында шикәр чире арту да күзәтелә. Сабыйларга күбрәк шушы чир аркасында инвалидлык куела. Татарстанның суд-медицина экспертизасы бюросының 5 нче экспертлар составы җитәкчесе Ильмира Саттарова да соңгы елда шикәр чиренең 1,5 процентка артуын әйтте.

– Гомумән, бу авыруның Россия күләмендә артуы күзәтелә. 2022 елда 1489 балада әлеге чир барлыгы ачыкланды, – диде ул.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш балалар эндокринологы Мария Шәйдуллина балалар арасында шикәр чире артуын кадрлар җитмәү белән дә аңлатты. Баксаң, республиканың кайбер районнарында сабыйларны зурларны дәвалаучы эндокринологлар кабул итә икән. Бу проблеманы хәл итәргә кирәк, диде ул.

– Шикәр чире үзеннән-үзе бетми. Табибларга мөрәҗәгать итмичә генә аннан котылып булмый. Күп очракта бала комага киткәч кенә анда авыру барлыгын ачыклыйлар, – диде ул.

Утырышта катнашкан Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева Татарстанның суд-медицина экспертизасы бюросы эшчәнлегенә уңай бәя биреп, аларга рәхмәтен җиткерде. Елның авыр булганын да искә төшерде. Әмма кайбер кимчелекләрне ачыкларга һәм сәбәпләрен табарга кирәк, диде. Тәнкыйть сүзенә ачуланмагыз, дип тә куйды.

Ул да үз чыгышында сабыйларның сәламәтлегенә тукталды.

– Шикәр авыруын ачыклаучы белгечләр кайда? Нигә районнарда аларга кытлык бар? Без моны ачыкларга тиеш. Республикада югары технологияле җиһазлар белән тәэмин ителгән медицина үзәкләре җитәрлек. Йөкле хатын-кызларга скрининг уздырылмыймы? Нәрсәне эшләп бетермибез? Йөкле хатын-кызларны тиешенчә карамыйлармы, әллә инде бала тапканда җәрәхәт очраклары күбәяме? – диде Ләйлә Фазлыева.

Премьер-министр урынбасары узган ел коллегиядә куелган бурычларны да искә төшерде. Ригель Низамовның документ эшләренең 96 проценты электрон башкарыла дигәненә дә, «Ник 100 процент түгел?» – дип сорады ул.

– Калган 4 процент нигә электрон рәвештә документ бирмәгән? Ачыкларга кирәк. Күрше Чувашия Республикасында бу эш 98 процент башкарылган бит. Олылар арасында инвалидлык куелу буенча беренче булган районнардагы хәлләрне дә белешергә кирәк. Сарманда нигә аларның саны арта? Физик мөмкинлеге чикләнгән сабыйлар саны күп булган районнарга да сорауларым бар. Безгә җыелышып сөйләшергә, моның сәбәпләрен ачыкларга кирәк, – диде ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республиканың нефть химиясе сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен хезмәт ветераны **Яхин** Илфар Рафикъ улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Республиканың финанс системасын үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы хезмәткәрләре: мәгарифтә бюджет сәясәте бүлеге башлыгы урынбасары **Бикбова** Земфира Илдар кызы, мәгълүмат куркынычсызлыгы бүлеге әйдәүче белгече **Зотагина** Елена Юрьевна, социаль-мәдәни өлкәдә бюджет сәясәте бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Таҗиева** Гөлназ Әннүр кызы, икътисад тармакларын финанслау бүлеге башлыгы **Шакирҗанова** Венера Энгель кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы хезмәткәрләре: икътисад тармакларын финанслау бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Габделхакова** Гөлүсә Габделфәт кызына, икътисад бүлеге башлыгы урынбасары **Кәримуллина** Ирина Григорьевнага, Татарстан Республикасы бюджетын төзүне һәм үтәүне оештыру бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Миронова** Елена Александровнага, Татарстан Республикасы Конституция суды финанс-икътисад бүлеге өлкән белгече **Заһретдинова** Ландыш Искәндәр кызына, «Әлмәтнең «Алсу» оек-оекбаш фабрикасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Ишморатова** Юлия Владимировнага **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Мөслим МСО» акционер җәмгыяте субподрядчысы **Хаҗиев** Вазыйх Әхмәтгаян улына **«Татарстан Республикасының атказанган энергетигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ДУСЛЫК КҮПЕРЕ

ТӨРЕКМӘНСТАН БЕЛӘН БЕЗНЕ НӘРСӘ БӘЙЛИ?

Россиядәге югары уку йортларында 30 меңнән артык төрекмән студенты белем ала. КФУда алар 4 мең чамасы. Минем өчен беренче югары белемемне нәкъ менә Россиядә, Казан федераль университетында алу – чын мәгънәсендә зур шатлык ул. Чөнки Төрекмәнстан һәм Россияне, аерым алганда, Татарстанны да бик тыгыз ике яклы хезмәттәшлек бәйли.

Төрекмәнстанда яшьләр сәясәтенә зур игътибар бирелә, алар өчен дөнья-күләм таләпләргә туры килә торган уңай шартлар тудырыла. Шул исәптән югары таләпләргә җавап бирә торган яшь белгечләр әзерләү дә әһәмиятле юнәлешләрдән санала. Бу нисбәттән Россиядәге мәгариф системасының тәҗрибәсен куллану дәүләт өчен кызыксыну уята. Төрекмәнстан һәм Россия арасындагы дипломатик мөнәсәбәтләрне раслаучы күпсанлы документлар арасында ике арада мәдәният, мәгариф һәм фән өлкәсендәге хезмәттәшлек турындагы килешүләр дә бар. Алар ике дәүләт арасындагы мәгариф һәм фәнни элемтәләрне ныгытуда зур роль башкара.

XXI гасыр башында ике дәүләт тә үзара дуслыкны һәм аңлашуны тагын да ныгыту өчен зур адымнар ясый. Аерым алганда, Россиянең әйдәп баручы югары уку йортларында Төрекмәнстан өчен кадрлар әзерләү программасы расланды. Хәзерге вакытта 30 меңнән артык төрекмән студенты Россиядәге югары уку йортларында белем ала. Бу җәһәттән Татарстан кебек төбәкләр белән бәйләнешләргә зур әһәмият бирелә.

Төрекмәнстан парламенты – Милли Генгешның Халык Маслахаты рәисе Гурбангулы Бердымөхәммәтов «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit 2022» Халыкара икътисадый саммитында хәзерге вакытта Татарстанда 5 меңләп төрекмән студенты белем алуын, ә республиканың фәнни-җитештерү өлкәсендә көчле потенциалга ия булуын искәртте.

Чыннан да, Татарстанда урнашкан югары уку йортларында белем алырга теләк белдерүчеләрнең саны елдан-ел арта бит. Шундый уку йортларының берсе – Казан федераль университеты. Хәзерге вакытта КФУда 4 меңләп төрекмән студенты белем ала. Ә монда укучы чит ил студентларының гомуми саны – 10 меңнән артык. Бу урында Төрекмәнстанның Казандагы Генераль консуллыгының КФУ белән уңышлы гына хезмәттәшлек итүен билгеләп үтәргә кирәк. Әлеге оешма һәм КФУ даими рәвештә уртак чаралар үткәрә.

turkmenportal.com

Төрекмәнстан белән Россия арасындагы үзара хезмәттәшлек тарихның хәзерге этабында ике ил халыклары арасындагы күпгасырлык дустанә мөнәсәбәтләрнең чагылышы булып тора. Әлеге ике дәүләтнең мәгариф һәм фән өлкәсендә хезмәттәшлек итүенең бай тәҗрибәсе бар. Бүген Төрекмәнстан да, Россия дә гуманитар диалогны алга таба тагын да киңәйтү өчен барлык мөмкинлекләргә ия.

Айгөл ХӨСЕЙИНОВА,
КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр институтының IV курс студенты

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырыгынчы утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырыгынчы утырышын 2023 елның 26 гыйнварында 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2023 елның 19 гыйнвары. № 1792-VI ДС

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Татарстан Республикасы Тәтеш районы территориаль сайлау комиссиясе составына ике вакантлы урынга, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, сайлау комиссиясе әгъзалары кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кабул итү турында хәбәре

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, Татарстан Республикасы Тәтеш районы территориаль сайлау комиссиясенең ике әгъзасы вәкаләтләренең вакытыннан алда туктатылуы сәбәпле, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 22, 26 һәм 29 статьяларына, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 11, 15 һәм 18 статьяларына таянып, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, Татарстан Республикасы Тәтеш районы территориаль сайлау комиссиясенең ике әгъзасын билгеләү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кабул итү турында игълан итә.

Документлар 2023 елның 23 гыйнварыннан 3 февральгә кадәр эш көннәрендә 09.00–18.00 сәгатькәчә (төшке аш вакыты: 12.00–13.00) түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420111, Казан ш., Батурин ур., 7 б й., (элемтәгә керү өчен телефон: 8(843) 292-84-33).

Территориаль сайлау комиссиясе составына вакантлы урынга кандидатура буенча тәкъдимнәр керткәндә, «Муниципаль берәмлекләрнең территориаль сайлау комиссияләрен, сайлау комиссияләрен, округ һәм участок сайлау комиссияләрен формалаштыру тәртибе турында методик рекомендацияләр хакында» 17 февраль, 2010 ел, № 192/1337-5 Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карарына таянырга кирәк.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе

ХА-ХА-ХАНӘ

Шушы урында көләсе

Булган хәлләр

КИРАМ САТИЕВ ҺӘМ ЗУР МӘЧТИ

Күренекле баянчы Кирам Сатиев Зур Мәчти дигән авылга концерт белән килеп чыга. Тамашадан соң мул гына банкет та оештырганнар. Колхоз рәисе Кирамга бәйләнепме-бәйләнә:

– Кирам, син – шәп баянчы. Син безнең авыл турында җыр язарга тиеш!

Кирам үзенең композитор түгеллеген дә аңлатып карый. Юк, бераз «кәгеп» алган рәистән һич котылып булмый. Ул музыка коралында уйный белгән һәр кешене көй яза ала дип уйлый.

– Яз, Кирам, яз. Акчасыннан тормам. Менә безнең бер шагыйрәбез сүзләрен язды, укып кара.

Нишләсен инде, акчасын мул түләргә вәгъдә биргәч, баянчы текстны укып чыга. Кушымта саен шундый сүзләр бар: «Зур Мәчтием, Зур Мәчтием…»

– Кара әле, агай-эне. Моны берәрсе сәхнәдән җырласа, тамашачы мактану дип уйларга мөмкин бит, – ди Кирам ага.

Шулай итеп, «Зур Мәчти авылы көе» дигән гаҗәеп гүзәл җыр… тумый кала.

МАРАТ ЗАКИРНЫҢ КИТАП КАЛЫНЛЫГЫ

Элегрәк еллар. Журналист, язучы Искәндәр Сираҗи каләмдәше Марат Закирны очрата.

– Котлыйм, Марат, китабың чыккан икән. Әле рецензиясен укыдым. Ну, мактаганнар, малай! «Кирпеч калынлыгы томнарга торырдай китап», – дигәннәр. Берәр экземплярын җай чыкканда миңа да кыстырып кил әле.

Марат сүзсез генә куен кесәсеннән юка гына бер китап чыгара. Искәндәр китапны болай әйләндереп карый, тегеләй боргалый да әйтеп куя:

– Карале, Марат, мин шундый яхшы рецензия укыгач, әле көнләшеп тә куйган идем. Минем хезмәт кенәгәсе дә синең бу китабыңнан калынрак икән бит!

РЕНАТ ВӘЛИУЛЛИН ТУКАЙГА МЕНГӘН

Бу кызык хәлне Татарстанның Санкт-Петербург шәһәре һәм Ленинград өлкәсе буенча даими вәкиле Ренат Вәлиуллин сөйләде. Билгеле булганча, төньяк башкалада Тукай һәйкәле бар. Шушы урында зур гына чара буласы, иртәгә зур кунаклар килергә тиеш. Бар да тәртип микән дип, Ренат әфәнде һәйкәл янына килә. Ни күзе белән күрсен: Тукаебыз иңбашына кошлар начар эшләрен эшләп куйган. Инде нишләргә? Вәлиуллин, ике дә уйламый, һәйкәл өстенә менеп китә. Тотынып менәргә аңа шоферы ярдәм итә. Өскә менү – бер хәл, анда менгәч егылмаска да кирәк бит әле. Берзаман һәйкәл селкенгән кебек итә. «Тукай белән бергә егылып төшсәк, Ренат Вәлиуллин Тукай һәйкәле өстенә менгән һәм аны җимергән, дигән яманат таралачак бит», – дип уйлап куя даими вәкил һәм тиз генә төшү ягын карый. Хәер, менүе юкка булмый, кошлар «күчтәнәч»ен чистартырга өлгерә ул. Һәм икенче көнне Тукай кунакларны чиста-пөхтә килеш каршы ала.

Тату һәм СПТУ

Татуировка ясату – СПТУга укырга керү белән бер. Шул бер үк сораулар ишетәсең:
– Куркыныч булмадымы?
– Ә күпме түләдең?
– Ә моның мәгънәсе нидә?
– Картлык көнеңне уйладыңмы?
– Сине болай эшкә алмаячаклар.
– 15 елдан соң нәрсәгә кирәк иде инде бу миңа, дип уйлаячаксың.
– Берәр авыру ияртмәссеңме соң?

Уйнаштан туган фикер

ҖЫРЧЫЛАРГА КУШАМАТ

Татар эстрадасында берәүләр санавы буенча 700дән артык, икенчеләр статистикасы буенча берничә мең җырчы бар. Аларны истә калдыру бүген зур проблема. Кешегә кушамат тагу – татарның элеккедән килгән гүзәл бер гадәте. Элек авылда кушаматсыз кеше булмаган. Бигрәк тә адашларың булса – беттең, икенче исемеңне көт тә тор! Кемгәдер кушамат индивидуаль рәвештә тагылган, кемгәдер нәсел мирасы булып. Хәзер авылларда бу гадәт бетеп килә (хәзер авылларда кеше бетеп килә, дисәң, дөресрәк булыр). Әмма бу матур традицияне эстрадада дәвам итәргә була бит. Лилия, Ләйсән, Гөлнара, Илназ, Илдар, Илнурларны, ниһаять, аера башлар идек. Хәер, күбесе инде бездән җитезрәк булды: үзләренә-үзләре кушамат тактылар: ИлСаф, Илназар, Илгәрәй һ.б. Эстрадада бу псевдоним дип атала, татарча итеп әйтсәк, тәхәллүс. Әмма үз-үзеңә кушамат тагу бик үк гадел түгел. Ә, бәлки, халык сине башка исем белән күзаллыйдыр?

Төрле тамашачыдан «әй, теге чиерткә», «тагын теге озынборын чыккан», «яратмыйм шул «мөгри»не» кебегрәк сүзләр ишетергә туры килә. Кайбер җырчыларның кушаматлары теге яки бу гаиләдә генә таралган булырга мөмкин. Бу атамалар киң җәмәгатьчелеккә чыга алмый. Ә бит чыкса, бик уңайлы булыр иде. Әйтик, клип башлана, титрларда язу: «Татар халык җыры «Күбәләгем-түгәрәгем». Башкара Кылый Бозау». Шундук истә калачак.

Айдар Галимовны армиядә Татарин дип йөрткәннәр, Салаватны яшь чакта Басмач дип, Хәния Фәрхи – Хай-Фай, «Айфара» Алмазы гомергә – Шампунь. Җырчылар кушаматлы булудан уңайсызланмасын берүк. Әнә зур түрәләрнең дә икенче исемнәре бар бит. Әйтик, «кичә телевизордан Бабай чыгыш ясады» дигәндә «Кайсы бабай?» дип сорамыйбыз.

Кушаматның төрле формасы бар. Сайлау мөмкинлеге бик зур. Әйтик, татар авылларында элек «фәләннең фәләне» дигән формулалы кушаматлар киң таралган булган. Алар кызның әтисе яки ире исеменә бәйле: Вәли Мәрзиясе, Госман Гайшәсе, Мәхмүт Суфиясы һ.б. Бу формуланы эстрадага күчерү аеруча актуаль. Бүген бик күп чибәр кызлар сәхнәгә үзләренең бай иганәчеләре хисабына менде. Җырчының кем акчасын туздыруына карап, кушамат тагарга була: «Кайсы фәлән ул?» «Соң, төгәннең фәләне ич инде!»

Кыскасы, җырчыларга кушамат кирәк бүген. Бу – «көнүзәк» мәсьәлә! Безгә аларны истә калдыру җиңелрәк булыр, ә аларны халыкка якынрак итәр. Әлбәттә, бу язмамдагы фикерләрем ярымшаяру иде. Татар җырчылары яхшымы, начармы – иң мөһиме, булсын алар. Сәхнәдә кемне калдырасын ахыр чиктә тамашачы хәл итә бит. Композитор һәм шагыйрьләр матур җырлар иҗат итсен, сәхнә амбицияләре ташып торган егет-кызлар шул әсәрләрне хит итәргә азаплансын. Ә кушаматларын гына табар идек әле…

Менәтерәк!

ТИЛЕ ТИЛЕВИЗОР



– Ә мин йога белән шөгыльләнәм, сәгатьләр буе бер җиргә карап утырам.
– Кайда инде ул җир?
– Телевизор экранында.

* * *

Телевизорда телсезләргә тәрҗемә итүче кеше яңалыклар урынына гел реклама гына сөйләп утырган.

* * *

Социологлар сөйләгән «суыткыч һәм телевизор тарткалашуы» булмаячак. Суыткычта ризык бетсә, ризыкны телевизордан күрсәтәчәкләр.

* * *

Мин телевизорны ничек карыйм:
– ТВ кабызам, анда реклама;
– башка каналга күчерәм, анда реклама;
– телевизорны сүндерәм.

* * *

– Лилия, кызым, синең курчагың кайда?
– Мин аны йокларга яткырдым, әни. Чөнки бу кино балалар өчен түгел.

* * *

Этем өйдә үзе генә курыкмасын дип телевизорны кабызып калдырган идем. Мин кайтып керүгә этем куркуыннан миңа менеп атланды.

* * *

– Нигә елыйсыз, балалар?
– Аның ужастик карыйсы килә, ә минем – фэнтези.
– Талашмагыз, мин сезгә хәзер үзәк канал яңалыкларын куям.

Әз-мәз мәзәк

– Кичә син хатын белән театрда булгансың икән.
– Ә нәрсә? Мин театр яратам.
– Ул минем хатын иде.

* * *

Мәзәкне аңламыйча, боксчы бик озак башын ватты.

* * *

Бар да идеаль эшләмәсә, борчылмагыз. Бар да идеаль эшләсә, сезне эштән куарлар иде.

* * *

Яңа хатынны сайлаганда, элекке хатыннарың алдында кызармаслык булсын.

Совет чоры кызыклары

Коры аш

КПСС райкомының беренче секретаре Әнвәр Баһаветдинов берчак Ык буе хуҗалыкларының берсендә үзенчә кызыклы һәм сәер сорауга төбәлеп кала: токмач – ипиме? Моңарчы ишеткәнем дә юк, дип куя.

Башкортстан белән чиктәш әкияти болынлыклар янәшәсендәге язгы чәчү бара торган басуга килеп төшкәч, төшке ашка җыелган тракторчыларның өлкәне колхоз рәисе Заһир Кашаповка сорау ташлый:

– Өч көн инде ипи күргән юк, коры аш ашыйбыз, кырыйдагы Вахитов совхозының пекарнясыннан алып булмый микәнни?

Дистә еллардан бирле колхозны җитәкләүче бу юлы да аптырап калмый, аш пешерүче хатыннарга карап:

– Нигә ул ашка токмачны күпләп салмыйсыз, мин үзем ипи беткәндә токмачны бик ошатам, – дип куя.

Шуннан беренче секретарь, токмач ипи була алмый, дип, рәисне совхозның пекарнясы янында төшереп калдыра.

Умарта карагы – үз улы

Безнең Түбән Стәрле авылында нарат йорты, андагы умарталыгы белән – менә мин шулай яшим, дип үзен үтә дә күрсәтергә яратучы Мотыйгулла абзый бар иде. Бик өлгер дә иде ул: өч чакрымдагы үзәк авылдан, ат җигеп, почта алып кайта, өстәвенә колхозның умарталыгын тота.

Берчак җәйге иртәдә умарталыгына килеп төшүгә, Мотыйгулла абзый туздырылган корт ояларын күреп өнсез кала. Бераз хәл алгач, милициягә шалтырата:

– Тизрәк килеп җитегез, умарталыгыбызны туздырганнар – ни карап ятасыз анда?

Шунда ук аңа:

– Умарта каракларын әле генә тотып алып кайттык, тизрәк килеп җитегез, – дип җавап бирәләр.

Мотыйгулла абзый бик ачулы барып җитә, милиция бүлмәсенә керә, ә аның каршына үзенең өлкән улы белән бер дустын бастыралар.

– Юк, юк, мин ялгыш, мин саташканмын, колхозныкы түгел, үземнең умарталар булган. Бу болай гына. Әйдә, улым, ялгышкансың, үзебезнең балны алырсың, колхозныкы харам, – дип тәүбә итәргә ашыккан Мотыйгулла абзый.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай шәһәре

Фотофакт

«АЙ ДА ПУШКИН! АЙ ДА МАТУР БУЛГАН!»

Бу фотоны күргәч, шулай диясе килә. Дагыстан башкаласы Махачкала шәһәрендәге бер урамда менә шушындый арт-объект бар. Диварга Александр Сергеевич сурәтен ясаганнар, ә чәчләре урынына агач ботаклары мач килгән. Хәер, казанлыларга мондый иҗади идея тансык түгел. Башкалабызның Восстание урамында зур гына каен агачын бер кыз бала су сиптереп «үстерә», әйтерсең, ул – лалә чәчәге. Әлеге рәсемнең авторы – стрит-арт рәссам Азат Алиев. Бакчагызда, якын-тирәгездә агачлар бармы? Бәлки, сезнең башыгызга да берәр идея килер? Әгәр дә бу язманы укыган ирегез бакчадан: «Хатын! Бир әле буяу белән пумала!» – дип кычкырса – чү! Димәк, сезнең бакчагызда да яңа арт-объект туарга мөмкин.

Әйтмәгән саен!

Мин һәм мин-минлек

Минем фамилия сыйныф журналында беренче тора иде, шуңа күрә миңа хәзер берни куркыныч түгел!

* * *

Никтер күңелсез. Тормыш планнарыгызны сөйләп, бераз көлдерегез әле мине.

* * *

Кәрәзле элемтә операторы миңа көненә егерме тапкыр шалтыратып, безнең эшебездә нәрсә ошамый, нәрсәне яхшыртыйк, дип сорый.

* * *

Буем – 198, авырлыгым – 120. Кара күзлек киеп, сезнең янда йөреп, кеше куркыта алам.

* * *

Вакыт машинасын кабыза алсам, мин киләчәккә түгел, узганга очар идем.

* * *

Бөтен нәрсәне ярышка әйләндерә торган кешеләрне очратканыгыз бармы? Мин аларны сезгә караганда күбрәк очраттым.

* * *

Таныш булмаган телефон номерларын алмыйм мин, чөнки ул танышым булырга мөмкин.



* * *

Бүген мине машина бәрдерә язды. Киләчәктә эшлисе булмаган бөтен эшләрем күз алдымнан узды.

* * *

Мин диварлар аша узарга телим, әмма миңа һәрвакыт нидер комачаулый.

Мач әйткән!

Бернар ВЕРБЕР, француз фәлсәфәчесе

Аңларга теләгән кеше генә аңлый ала.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5302 данә
Гомуми тираж – 15536 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 209

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+